**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**16.07.2019** г. Казань **№246**

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршында Журналистларны аккредитацияләү турындагы кагыйдәләрне раслау турында

1991 елның 27 декабреннән №2124-1 «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Россия Федерациясе Законының 48 статьясына туры китереп б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршында Журналистларны аккредитацияләү турындагы кагыйдәләрне расларга.

2. Министрлыкның Мәгълүмат һәм медиакоммуникацияләр секторына (З.Ф.Гыймазова) Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршында Журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Министрлыкның эшләр белән идарә итүче Э.М.Әхмәтгәрәевка йөкләргә.

**Министр** **Д.И.Фәттахов**

2019 елның 16 июлендә
246нчы номерлы боерык
нигезендә Яшьләр эшләре
министрлыгы тарафыннан
расланды

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршында
журналистларны аккредитацияләү
кагыйдәләре

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәләр 1991 елның 27 декабреннән №2124-1 номерлы «Массакүләммәгълүмат чаралары турында» Россия Федерациясе Законының 48 статьясына туры китереп Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы каршында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү тәртибен регламентлый (алга таба – аккредитацияләү, министрлык).

1.2. Аккредитацияләү срогы бернинди чикләүләрсез гамәлгә ашырыла. Массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе теләге белән аккредитацияләү билгеле редакция биремен үтәү өчен кирәк булган срокка, яисә аккредитацияләнгән журналистның алмаштыру өчен җибәрелгән башка журналистны вакытлыча аккредитацияләү максатыннан башкарылырга мөмкин (вакытлыча аккредитацияләү).

II. Аккредитацияләү алу хокукы

2.1. Право на аккредитацию имеют редакции средств массовой информации независимо от формы собственности и состава учредителей, в том числе зарубежные средства массовой информации. Для аккредитации журналиста зарубежного средства массовой информации необходимо подтверждение его аккредитации при Министерстве иностранных дел Российской Федерации.

Милек формасына һәм гамәлгә куючыларның составына карамастан, һәр журналист, шул исәптән, чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары, аккредитация алырга хокуклы. Чит ил массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясеннән булган журналистны аккредитацияләү өчен, журналистның Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация алуы зарур.

III. Аккредитацияләү тәртибе

3.1. Аккредитацияләүгә гариза массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе тарафыннан имзаланып, гариза тапшыру фактын, көнен һәм вакытын раслый алырлык теләсә нинди ысул белән Министрлыкка тапшырыла.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), журналистның вазыйфасы, эш һәм кесә телефоны, массакүләм мәгълүмат чарасынының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү таныклыгының номеры һәм датасы күрсәтелгән булырга тиеш.

Вакытлыча аккредитация гаризасында үтәлергә тиешле бирем һәм аны кайсы срокта үтәлергә тиешлеге күрсәтелә. Аккредитацияләнгән журналистны, аның

вакытлыча булмавы аркасында, башка бер журналист белән алмаштырган очракта, яңа журналистның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта) һәм әлеге аккредитациянең кайсы срокка булуы күрсәтелергә тиеш.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чарасыннан булган журналистны аккредитацияләү өчен, өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация алу кәгазен дә беркетергә кирәк.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмыйлар.

3.4. Аккредитацияләү турында (аккредитацияләүдән баш тарту турында) карар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба –министр) тарафыннан гариза кергән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә. Мондый карар министрның тиешле боерыгы чыгарылган көннән башлап киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гаризаны җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә, аның редакция тарафыннан алыну фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә нинди ысул белән җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чарасы махсуслаштырылган характерда (реклама тарату, эротик басмалар) булган очракта, аккредитацияләүдә баш тартыла.

3.6. Гаризаны карау, аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турында министр боерыгы проектын әзерләү, шулай ук массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә кабул ителгән карар турында хәбәр итү Министрлыкның мәгълүмат һәм медиакоммуникацияләр секретаре тарафыннан әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәгеләргә хокуклы:

чарада катнашырга;

Министрлык карамагында булган чара турында рәсми документларның (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материаллар) күчермәләрен алырга;

бастырып чыгару өчен билгеләнгән мәгълүмати-белешмә материаллар белән танышырга;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар бурычлы:

әгәр чара массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган булса, чараның регламентын үтәргә һәм аның барышына комачауламаска;

чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламаска;

публикацияләрдә (эфирда эшләгәндә) Министрлык тарафыннан бирелгән пресс-релизлардан, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материаллардан файдаланганда мәгълүмат чыганагына сылтама бирергә;

үзенең һөнәри эшчәнлеген тормышка ашырганда, Министрлык эшчәнлеге турында чынбарлыкка туры килми торган мәгълүматларны таратмаска.

---